СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.09.2022 Баулы шәһәре №133

Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 12 декабрендәге “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләк тапшыру һәм аны бәяләү, сату (сатып алу) һәм реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе хакында” карарына өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы «Аерым категория затларның беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны тормышка ашыру (сатып алу) һәм реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында хәбәр итү тәртибе хакында” карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 12 декабрендәге “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләк тапшыру һәм аны бәяләү, сату (сатып алу) һәм реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе хакында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль

хезмәткәрләре һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләк тапшыру һәм аны бәяләү, сату (сатып алу) һәм реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында нигезләмәгә

түбәндәге өстәмәге кертергә:

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле 13.1 пунктча өстәргә:

«13.1. Кыйммәтле металлардан һәм (яисә) кыйммәтле ташлардан әзерләнгән бүләккә муниципаль вазифаларны, муниципаль хезмәт вазифасын биләүче затлардан әлеге нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза килмәгән очракта, йә күрсәтелгән затлар мондый бүләкне сатып алудан баш тарткан очракта, кыйммәтле металлардан һәм (яисә) кыйммәтле ташлардан әзерләнгән бүләк Бүләк алу буенча бәя комиссиясе тарафыннан, Россия Федерациясенең Кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар фондына күчерү өчен, «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы кыйммәтле металл һәм кыйммәтле ташлар Дәүләт фондын төзү, саклау, җибәрү һәм алардан файдалану буенча дәүләт учреждениесе» федераль казна учреждениесенә тапшырыла.

2. Баулы муниципаль районы муниципаль вазифаларын биләүче затлардан һәм Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләреннән беркетмә чаралары, командировкалар һәм аларда катнашу аларның хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда алынган бүләкләрне муниципаль милеккә кабул итү буенча бәяләү комиссиясе составын 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
вазифаларын башкаручы, район Советы
Рәисе вазифаларын башкаручы Р.Г. Хәмидуллин

«Баулы
муниципаль районы Советының
2019 елның 12 декабрендәге
240 номерлы карарының 4 нче
кушымта

Баулы
муниципаль районы Советының
2022 елның __________
___ номерлы карары
редакциясендә

Баулы муниципаль районы муниципаль вазифаларын биләүче затлардан һәм Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләреннән беркетмә чаралары, командировкалар һәм аларда катнашу аларның хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда алынган бүләкләрне муниципаль милеккә кабул итү буенча бәяләү комиссиясе составы

1. Баулы муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе;

2. Баулы муниципаль районы башлыгы урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары;

3. Баулы муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар белән тәэмин итү бүлеге начальнигы, Комиссия секретаре

Комиссия әгъзалары:

4. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары;

5. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе;
6. Баулы муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе;
7. Баулы муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе;
8. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Контроль-хисап палатасы»МКУ рәисе;
9. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы»МКУ җитәкчесе;
10. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы»МКУ җитәкчесе;
11. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлек начальнигы;
12. Баулы муниципаль районы Советы Аппаратының бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлеге начальнигы;
13. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге начальнигы.